КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 июль г.Казань № 545

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (механизм карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен (алга таба – Тәртип);

Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составын.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Тәртипкә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин